Татарстан яшьләре

№ 68

(3496)

СИШӘМБЕ

11 июнь, 1991 ел

Бәясе 10 тиен.

ЯШЬЛӘРНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ • 1920 ЕЛНЫҢ 22 ГЫЙНВАРЕННАН БИРЛЕ ЧЫГА

Кайчан? Кайда? Нәрсә?

УЗГАН ШИМБӘ-ЯКШӘМБЕ көннәрендә җөмһүриятебез авылларында һәм район үзәкләрендә Сабантуйлар узды. Аларга җыелган халыкның кайбер өлешен, күңелле тамашалардан тыш, төрле бәйгеләрдә җиңүчеләргә нәрсә бирелүе кызыксындыргандыр, мөгаен. Нишлисең, шундый кытлык замана. Кыскасы, Сабантуйлар батырлар ярышы белән генә түгел, аларны оештыручылар ярышы белән дә истә калды.

«АЗАТЛЫК» татар яшьләре берлеге сәяси белдерү белән чыкты. Аның лидерлары җөмһүриятебездә яшәүчеләрне РСФСР Президентын сайлауда катнашмаска, ТССР президентлыгына бердәнбер дәгъвачы Минтимер Шәймиевнең, нинди генә тискәре сыйфатләре булса да, аның өчен тавыш бирергә чакыралар. Нәрсә генә булмасын, Татарстан җирендә Ельцин, Бакатин, Рыжков, Жириновский, Тулеев, Макашов кебек Рәсәй «патшалары» түгел, бәлки татар Шәймиевләре хуҗа булырга тиеш. РСФСР Президенты безнең өчен түгел, шуңа күрә сайлау участокларында андый бюллетеньнәрне бөтенләй кулга алмаска кирәк.

23 ИЮНЬДӘ мөселманнарның иң олуг бәйрәме — Корбан бәйрәме булачак. Шушы уңайдан «Иман» ислам мәдәниятын өйрәнү мәркәзе 15 июньдә 19 сәгатьтә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында зур кичә үткәрә. Анда дин әһелләре, галимнәр, язучылар, артистлар катнашачак. Килүчеләргә зәвык белән эшләнгән шәмаилләр һәм ислам матбугаты тәкъдим ителәчәк.

12 ИЮНЬ көне гадәти эш көне санала. Аны ял көне итү турында ТССР Югары Советында сөйләшүләр булса да, алар чынга ашмады. Әмма кайбер производство җитәкчеләре моның белән килешергә теләмәде. Мәсәлән, А. П. Горбунов исемендәге Казан авиация производство берләшмәсендә ТССР Президентын сайлаулар көне ял көне дип игълан ителде.

ӘЙБЕР БӘЯЛӘРЕ күтәрелү белән истә калачак 2 апрельдән соң... кайбер товарларның бәясе төшә башлады. Казанның Киров урамындагы «Букинист» кибетендә, мәсәлән, «Ленин тормышы» дигән 10 томлык нибары 12 сум торса, Сталин әсәрләренең һәр томын исә хәзер 200—250 сумга саталар, яисә кыйммәтле чит ил гарнитурына алыштыралар.

Айрат ИЛСУМ.

МАТУРЛЫККА МӘДХИЯ

Өйе, 6 июньдә Мәгариф хезмәткәрләре йортында үткәрелгән чәчәкләр күргәзмәсен шулай дип тә атарга мөмкин иде. Биредә ул көнне күз явын алырдай пионнар, миләүшәләр, гөлчәчәкләр тантана итте. Күргәзмәне республиканың чәчәк үстерүчеләр секциясе әгъзалары оештырды. Теләкләре булганнар чәчәк бәйләмнәре, шытымнар һәм орлыклар сатып алдылар.

Е. КАНАЕВ фотосурәтләре.

Укыдыгызмы, ишеттегезме...

НОВОСИБИРСКИДА Александр Солженицынның «Архипелаг ГУЛАГ» китабының беренче нөсхәләре 30—50-нче елларда Сталин лагерьлары михнәтләрен кичерүчеләргә бирелде.

• • •

РОССИЯ телевидениесе буенча үткәргән матбугат конференциясендә Борис Ельцин, Союз килешүен төзүдә Россия өчен бердәнбер каршылыкны Татарстан тудыра, дип белдерде.

Көнгә аваздаш шигырь

Фәсим ГАШИМОВ

Берләшегез!

Әй мөкатдәс халкым, илгенәм!
Чал тарихлар аша киләбез,
Җир әйләнә. Вакыт тирә-якта,
Вакыт корабында йөзәбез.

Вакыт, заман — иң кадерле нәрсә,
Вакыт ага, китә, югала.
Яшәү исә көрәш таләп итә.
Бар халыклар шуңа кузгала!

Бүген анда, Идел ярларында,
Ирек мәйданында туганнар.
Халык күңеле хәрлек, ирек даулый,
Бергә булыйк, газиз туганнар!

Яшәү кирәк, дуслар, халык булгач,
Пыскып яту дәүләт китерми.
Таралганбыз, диеп зар елаулар
Җиңү юлларына җиткерми.

Без — ут, яшен, җиһан балалары,
Кояш көче ага каннарда.
Бәйсез, горур, азат халык булу
Тумыштан ук безнең җаннарда.

Без мескеннәр түгел! Ялгышмагыз!
Бәхет безнең белән, күрегез!
Мөмкинлекләр безнең чикләнмәгән,
Ут йөрәкле була белегез!

Ил-йортыбыз, Казан-ана бүген
Ирек мәйданына җыйналган.
Намусыбыз безнең — көчле байрак,
Көрәш юлларыбыз уйланган.

Ил бәхетсез булмас, сөйләмәгез,
Шундый кыз-уллары булганда,
Азаматлар булып очу кирәк, —
Җиңү туа бары юлларда!

Берләшегез, дуслар! Сайлауларда
Ил агасын алга сөриек!

Таркалмасын бердәм тавышыбыз —
Минтимергә тавыш бириек!

Көчле булып типсен безнең йөрәк,
Күңел дәрте уңыш китерсен.
Рух, ихтыяр, ныклык, зиһен көче
Азатлыкка илтеп җиткерсен!

Башкортстан, Кандыра районы.

Нәҗибә САФИНА

Башкача — юк!

Татар каберендә ләхет булган ди...
452 ел элек бәхет булган ди...

Каберенә ләхет уеп татар
Куя иде сүнгән гәүдәләрне.
Өмет кала иде... җыя иде
Ирек килер, дигән бәндәләрне,

Ишелгәнче ләхет саклап торган
Авазларын шушы гәүдәләрнең,
Ләхетләрне җимерүче булып
Күз алдымда бүген гәүдәләндең.

Үз җиремнең ком-туфрагы бүген
Авазымны килеп томалады.
Ничә гасыр йомшак җәя-җәя,
Баскак көчләр безне юмалады.

Ләхетендә сулар һава табып,
Җанын саклап яткан татар бүген
Кицәйтмәкче иде ләхетенең
Хет әйләнеп бераз ятар күген...

Ләхет төбе бик тиз сизеп алды —
Ләхет күге тагы авырайды.
Кол булганчы, үтер, баскын, диеп
Аяк асларына аваргамы?

Син җантимер булсаң, әйт:
«Мин — Тимер,
Халыкка мин — ирек калканы, — дип,
Халык кисе белән шаярмагыз,
Шул учакның мин, дип, ялкыны бит!»
бит!»

Һәм кул куйма коллыкнамәсенә,
Ләхет түгел, бәхет кирәк безгә —
Коллыкнамәсенә кул куймаска
Туры карап әйт син бүген йөзгә!

Баш өстенә икмәк тотып әйтсәң,
Ышаначак халык синең сүзгә...
Башкача — юк!!!

СПОРТ•СПОРТ•СПОРТ

РОСТОВ-ДОН шәһәрендә академик ишү буенча «Дон регатасы» дигән ярышлар узды. Анда Татарстан вәкилләре дә чыгыш ясады. Тренер Татьяна Карагланова шәкерте — динамочы спорт мастеры Татьяна Борисова-Захватаева, ике экипаж составында ярышып, беренче һәм икенче урыннарны яулады. Ә менә сигез кешелек көймәдә узышкан Вероника Устинова, Светлана Зиновьева, Ольга Бельнюшкина, Валентина Алексеева өченче урын белән канәгатьләнделәр.

ТВЕРЬДӘ Афанасий Никитин призына узган регатада да Казан динамочылары сынатмады. СССРның атказанган тренеры Сергей Ульянов җитәкчелегендә күнегүләр үтүче Устинова, Зиновьева, Бельнюшкина, Алексеева финишка ике тапкыр беренче булып килделәр. Владимир Гоголин шәкертләре Альберт Хәсәнов, Игорь Галицкий, Алексей Киндеревич та пьедесталның иң югары баскычына күтәрелделәр. Халыкара класслы спорт мастеры Александр Устинов исә ялгыз ярышучылар арасында өченче урынга чыкты.

Лев СОСНИН.
(Штаттан тыш хәбәрчебез).

Бер башка ике бүрек кимиләр

ПРЕЗИДЕНТ САЙЛАУЛАРЫ УҢАЕННАН ТАТАР ИҖТИМАГЫЙ ҮЗӘГЕ БЕЛДЕРҮЕ

Халкыбызның сәяси һәм милли үзаңы, иман ныклыгы сыналыр көн якынлаша: 12 июнь — республикабызда Президент сайлаулары.

Татарстан халкы үз байлыгына хуҗа булып, башка союздаш республикалар белән тигез дәрәҗәдәге мөстәкыйльлеккә ирешә алырмы, әллә Россия һәм СССР составында саналып, ике хуҗаның хезмәтчесе хәлендә хокуксызлыкта гомер итәрме?

Хәл катлаулы: күптән түгел булып узган Татарстан Югары Советы сессиясендә «республикада РСФСР Президентын сайлауны рәсми рәвештә үткәрмәскә» дигән карар кабул ителде. Шул ук вакытта карарга, закон нигезендә теләгән кешеләргә сайлау көнендә РСФСР Президентын сайларга булышлык күрсәтелә, дигән пункт та өстәлде. Шуннан файдаланып, Татарстанда яшәп тә үзләрен Россия гражданнары итеп санаучы, республикабызның мөстәкыйльлеген, татар халкының изге омтылышларын танырга теләмәүче даирәләр РСФСР Президентын сайлау буенча зур кампания башлап җибәрделәр. Алар сессия чыгарган карарга рәсми төс бирергә омтылалар. Әлеге гамәлнең куркыныч ягы шунда: әгәр Татарстан халкының яртысы һәм плюс бер кеше РСФСР Президентын сайларга килеп, шул килгән халыкның яртысыннан артыгы уңай тавыш бирсә, Татарстанда Россия Президенты сайланган булып чыга. Бу исә, Татарстан Югары Советы сессиясендә кабул ителгән карарда «Сайлау республика мөстәкыйльлеге нигезләренә кагылмый» дигән пункт булуга да карамастан (без әле барлык карарлар да, законнар да төгәл үтәлә торган хокукый дәүләттә яшәмибез), РСФСР Президентының алга таба Татарстан эшләренә турыдан-туры катнашуына мөмкинлек калдыра.

Татарстан Президентын сайлау буенча ТИҮнең карашы эзлекле булды: 27 майга кадәр ул элегрәк Югары Совет сессиясендә кабул ителгән «Татарстанда РСФСР Президентын сайлау турында»гы карарны үзгәртү өчен төрле юллар белән көрәш алып барды һәм өлешчә максатына иреште һәм ул бу вакыт аралыгында Татарстанда РСФСР Президентын сайламаска өндәде. Хәзер ТИҮ барлык халыкны Татарстан Президентын сайларга чакыра. Республикабызда һәм Союз органнарында мөстәкыйльлекне яклау һәм ныгыту өчен көчле ихтыярлы, тәҗрибәле җитәкче — Президент кирәклеге бәхәссез мәсьәлә. Без бу постка тәкъдим ителгән М. Шәймиевне хәзерге катлаулы чорда республика белән идарә итә алырдай тәҗрибәле шәхес дип күрсәтәбез. Республикабыз сәяси тормышындагы текә борылышларда кайчак икеләнеп, сәяси хәлгә һәрчак дөрес бәя бирә алмаган очраклары булуга карамастан, аның потенциаль мөмкинлекләре зур булуын да таныйбыз. Без бөтен республика халкын Татарстанның якты киләчәге — мөстәкыйльлеге хакына М. Шәймиевне сайларга чакырабыз. Ә мөстәкыйльлегебезне шик астына куя торган гамәлдә, республика территориясендә РСФСР Президентын сайлауларда бөтенләй катнашмаска тәкъдим итәбез.

Республикада ике Президент идарә итүенә юл куймыйк, кадерле иптәшләр!

КАЯ КИТӘ БУ ТАТАР ?!

[Ахыры. Башы 66 нчы санда].

Гасырлар аша бу көннәргәчә килеп җиткән мәкальләрдән күренгәнчә, безнең ерак бабаларыбыз да гадел фикерләр әйтеп калдырганнар. Мәсәлән, «Өй өстендә өй булыр, ил өстендә ил булмас», «Ике ат башы бер казанга сыймый, ике патша башы бер мәмләкәткә сыймый», «Сәясәт үрмәкүч пәрәвезе кебек: чебен аны килеп эләккәч кенә күрә» кебегрәк мәкальләрнең раслыгын бүген дә кире кагарлык түгел.

Ләкин Рәсәй хакимияте тарихының буеннан-буена үз иленең «аскы катында» башка илләрне булдырырга тырыша. Ни өчен? Чөнки аның нәфесе һаман да яңадан-яңа дәүләтләрне басып алуга, талауга юнәлгән. Урыс патшалары Төркия, Франция, Германия, Польша кебек дәүләтләр белән низаг чыгара тора, ә элек буйсындырылган милләтләр, Рәсәй солдатлары сурәтендә утка керә тора, кырыла тора. Ягъни бер атуда ике куян: эчке дошманы да кырыла урысның, тышкы дошманы да... Ә барлык отыш үзенә— дан да, өстәмә биләмәләр дә, хакимият тә, ганимәт маллар да.

Татар халкыннан котылуга урыс патшалары аеруча зур тырышлык багышлый. Чөнки басып алынган биләмәләр киңәйгән саен Россиянең уртасында калган Казан ханлыгы бугазга тыгылган сөяккә әверелә. Татар әле күп икән, аның дәүләтчелеге, теле, мәдәнияты саклана икән, бу җирләрне Россия җире дип игълан итү мөмкин түгел. Моңа ирешү өчен бары тик ике юл кала: я үлемгә дучар итү, я табигать биргән, тарих ныгыткан үзенчәлекләрен бетерү.

Патшаның агы да патша, алы да патша, дигән безнең халык. Бу мәкаль, мөгаен, тарихка Бөек Октябрь революциясе исеме белән кергән 17 нче елгы бөек террордан соң тугандыр... «Бөек милләтнең» сәяси лидерлары властька омтылу чорында вак милләтләр тагын бер мәртәбә таптала, тагын бер мәртәбә кырыла. Дөнья бераз тынычланды дияргә өлгерми халык, дистәләрчә миллион җаннарны кырячак ачлык килә...

1552 нче һәм 1921-22 нче еллар, мөгаен, татар халкының кырылуына, таркалуына бер дәрәҗәдә этәреш китергән еллардыр. Бу ачлыкның афәтен күзаллау өчен рәсми мәгълүматларга игътибар итик: 1922 елның 1 январена Татарстан җирендә эшкә ярарлык кешеләр 2,8 миллион исәпләнә. Шуларның нибары 94 мең, ягъни 3 проценты гына читтән ярдәм алмыйча исән калырлык дип санала. 2 миллион 261 мең кеше үлемгә дучар ителгән. Исән калган балалар бер миллионга да тулмый, димәк, кайбер гаиләләрдә берәү дә калмаган.

Хәзер инде ачлык алдыннан булган кайбер саннарны да барлап карыйк. 1920 елның ахырында һәм 1921 елның башында продразверстка оештырыла. Татарстаннан 10.000.000 поттан артык ашлык, 2.000.000 пот чамасы бәрәңге, 500.000 поттан аз гына ким ит, 30.000.000 йомырка, 25.000 пот май һәм башка азык-төлек чыгарыла. Ризыксыз калдыруның тагын бер юлы табыла: крестьяннарга базарда азык-төлек сату тыела, бары тик кибетләргә тапшыру рөхсәт ителә. Бу кадәресе дә, әлбәттә, Татарстан җиреннән читкә чыгарыла.

Инде исәпләп карыйк: шушы кадәр нигъмәт халыкның үзендә калса, миллионлап кырылыр идеме милләт? Сүзне озайтмау өчен, мин бу исәп-хисапны укучының үзенә калдырам да, шул чорның сәяси мохитын ачыклап үтәргә тырышам. 1921 елның 7 октябрендә Арал диңгезе балыкчыларына адресланган мөрәҗәгатендә Ленин, капиталистлар ярдәменә исәп тота алмыйбыз, ул канэчкечләр, шушы ачлыктан файдаланып, безне азатлыктан м ә х р ү м итәргә генә ниятлиләр, дигән фикерне үткәрә. Ләкин игътибарыбызны 70 ел артка юнәлтсәк, күрәбез: кырылып бетмәвебезгә бары тик шул «дошманнар» —капиталистлар сәбәпче. Ленин илләр арасына ут салучы әлеге мөрәҗәгатен язганчы ук (!) Казанга 3000 пот азык-төлек төяп Американың ярдәм комиссиясе к и л е п төшә. Беренче көннәрдә бу комиссия 63.000 баланы туйдыра, бераздан 150.000 сабыйны үз канаты астына ала һәм ярдәмне айдан-айга көчәйтә бара. Яше 80 тирәсендә булган өлкәннәр белән сөйләшегез әле шул ачлык турында, хөрмәтле укучылар. Алар: «Бары тик Америка аркасында гына исән калдык»,— диярләр. Ә бу чорда Мәскәүнең ярдәме нәрсәдән гыйбарәт? Мәскәү властьлары нибары 6000 кешенең тамагын туйдырып, шулардан Татарстан урманнарын кистерә, башка өлкәләргә саллар чыгарта...

«Хурлыйлар, таптыйлар — миннән яхшыны тапмыйлар» дигәндәй, нинди ил бу Америка? Без аны 74 ел сүгәбез, ә ул я ачлыктан, я безнең хакимият үз башы белән барып кергән сугыштан коткара, фәнебезне, экономикабызны көчәйтергә тырыша... Гаҗәп ил, сәер ил, валлаһи! Аның кебек цивилизацияле илләрнең кануни һәм матди ярдәмен тоеп яшәмәсәк, кем белә, без хәзер «Кая китә бу татар?!» диясе урынга, «Кая китте бу татар?!» дияр идек инде, бәлки...

• • •

Дөрләп янучы корабтан матрослар, пассажирлар качкан шикелле, Россия империясенең (СССРдан дисәң дә аермасы юк) кабаласыннан, коллыгыннан халыклар, дәүләтләр кача. Хәтта санап өлгереп булмый: Румыния, Польша, Венгрия, Болгария, Чехословакия, Германия, Латвия, Литва, Эстония, Әрмәнстан ,Грузия, Молдова... Союз дигән империядәге башка халыклар да тыныч түгел, алар да азатлыкка, мөстәкыйльлеккә омтыла. Чыгып китүченең артына тибеп калучы кеше сыман, империя һәркайсында канлы бәрелешләр оештыра, һаман да куркытырга, кире кайтарырга, кабат буйсындырырга омтыла. Фани дөнья мисалларыннан һәркайсыбыз күреп тора: хатының яки ирең ташлап китә башласа да әллә нишләр хәлең юк — яратмый икән, синең белән бергә яшәргә теләми икән, авыр булса да юл бирәсең, араңны бозып бетермим әле, бәлки, акылга утырып кире кайтыр дип өметләнәсең. Һәрхәлдә әйбәтләп саубуллашырга тырышасың. Ә империя даирәләрендә әнә шул гапгади (элементар) тәртип тә юк, һичшиксез кыйнарга, үтерергә кирәк икән...

Минем бу хакта иркенрәк сөйләвем сәясәтне аңлавымны күрсәтергә омтылудан түгел. Хикмәт шунда, мәсьәләнең, язмышның иң катлаулысы һәм хәтәре безгә кала. Бая санап үткән дәүләтләр барысы да Рәсәйдән читтә, ә без, кабатлап әйтәм, урта бер җирендә.

Рәсәй безне хәер-фатиха биреп башка чыгарыр дигән фикердә йөрүче беркатлылар юктыр дип беләм. Шуңа күрә ике юлның берсен генә сайларга кала: я элеккечә баш иеп яшәү, милләт буларак бетүгә юл тоту, я бәйсезлек өчен көрәш. Тегесе дә хәтәр, монысы да куркыныч... Билгеле, милләтнең үсеше, сакланышы өчен өметле ук булмаса да, өченче юл да бар: анысы — аерылып чыгарга өлгермәгән республикалар белән тигез хокукта союзга керү. Киләчәктә ничек булыр, белгән юк, әле аңа да РСФСР составында гына кабул итәргә ниятләүләре сизелеп тора. Ягъни һаман да кол сыйфатында гына...

Кол дигәннән, холкына, халәтенә, мохитына һәм башка сыйфатларына карап, гыйлем ияләре колларны биш төркемгә бүләләр. Хәзерге хәлебезне аңлау өчен ул төркемнәрне белү дә бик зарур:

1. Үзләренең кол икәнлекләрен аңламаучы коллар.

2. Үзләренең кол икәнлекләрен белүче һәм шуңа... сөенүче коллар.

3. Үзләренең кол икәнлекләрен белүче һәм шуңа риза-бәхил коллар.

4. Үзләренең кол икәнлекләрен аңлап көенүче коллар.

5. Азатлык, мөстәкыйльлек яулау өчен көрәшкә күтәрелгән коллар.

Беренче төркемгә без берчакта да кермәдек, минемчә. 5—6 елда, ягъни үзгәртеп кору чорында икенче һәм өченче төркемнән дә чыктык сыман. Хәзер, мөгаен, без дүртенче төркем колларыдыр. Ләкин көенеп, кайгырып кына бер колның да бәйсезлек яулый алганы юк. Димәк, алда көрәш тора.

Дөрес аңлашылсын, мин, мәсәлән, бер генә җанның да кыелуын т е л ә м и м. Дөньякүләм кешелекнең үзаңы гуманлы кыйблага юнәлгән бу чорда урыс хакимиятендәге кешеләр дә яңача уйлыйдыр, безнең милләтне кабат-кабат канга батыруга ашкынып тормыйдыр дип өметләнәсе килә. Чөнки «Халыкара гражданлык һәм сәяси хокуклар пакты»ның беренче пунктында ук болай диелә: «Бөтен халыклар да үзбилгеләнүгә хокуклы. Бу максатта алар үзләренең сәяси статусларын ирекле билгелиләр, үзләренең икътисади (экономик), социаль һәм мәдәни үсешләрен ирекле тәэмин итәләр». «Ирекле» дигән сүз кат-кат кабатланган бу пактка безнең ил җитәкчеләре дә кул куйган. Ләкин күңелгә шик тә йөгергәли. Ник дигәндә, империя җитәкчеләренең йөкләмә һәм килешүләрне бик еш бозуларын, санга сукмауларын беләбез. Шуңа күрә мәгълүм пактка да хыянәт итүләре, империяне саклап калу максатында теләсә нинди адымга барулары ихтимал. Чөнки без «бөек милләткә» сугылачак көлтә, кимереләчәк калҗа, суырылачак нефть, савылачак сыер буларак кадерле. Әмма авыз тутырып әйткән сүзләре бөтенләй башка: янәсе, вак дәүләтләр мөстәкыйль булып яшәргә сәләтле түгел... Әгәр дә моны чын хакыйкать итеп танырга уйласак, Җир шарында Татарстаннан да бәләкәйрәк 104 мөстәкыйль дәүләт барлыгын истән чыгармаска тиешбез. Гасырлар буе яшиләр ләбаса! Әле кайберләре Татарстаннан 20—30 мәртәбә бәләкәйрәк. Халык саны ягыннан карасак та күрәбез: 126 дәүләтнең халкы татар халкыннан азрак. Яшиләр, зур илләр белән сәүдә итәләр, Берләшкән Милләтләр Оешмасында тигез хокуклы әгъза булып торалар! Инде Татарстанны РСФСР үзәгендә дип шикләнү һәм икеләнү дә урынсыз. Көньяк Африка Республикасының нәкъ уртасында, мәсәлән, Лесото дигән дәүләт бар. Басып та алмыйлар, буйсындыру турында да хыялланмыйлар үзен уратып алган күршеләре. Кыскасы, мондый дәүләтләр дә планетада шактый. Күршеләре юньле булса, безнең Татарстан да, һичшиксез, суверен хәлдә көн итә алачак.

Һәрхәлдә киләчәкнең юлы кабат берчакта да яшәлгән коллыкка борылып кайтмаска тиеш.

• • •

Ләкин милләтнең киләчәге Татарстан һәм Мәскәү фәрманнары белән генә, ачыклабрак әйтсәк, вәкаләтле җитәкчеләрнең һәм төрле дәрәҗәдәге депутатларның карарлары, законнары белән генә хәл ителә торган нәрсә түгел. Бу проблема тулаем диярлек милләтнең үзеннән, аның нинди булуыннан тора. Таркау милләт, үзенең язмышына битараф милләт берничек тә чын бәйсезлеккә ирешә алмый. Татарны һәркайда мескен иткән ачы хакыйкать һәркемгә мәгълүм бит: безнең халыкның нибары чирек өлеше Татарстанның үзендә. Хәзер, шушыннан чыгып, тагын бер мәртәбә арифметикага әйләнеп кайтыйк. Фаразан, Мәскәү даирәләре безнең республикага үзенчәлекле референдум уткәрүне көчләп тактылар ди. Ягъни Татарстанның суверенлыгын яклаучы кешеләр күбрәкме, әллә каршыларммы? Ә халыкның нибары 48 проценты татарлар... Кемнәргә таянырга, нәрсәгә исәп тотарга тиеш бу очракта Татарстан? Дөрес, Татарстаннан, РСФСРдан читтә яшәүче татарлар да милләтнең, республиканың бәйсезлеген телиләр. Әмма тормыш теләк белән генә бармый. Әйтик, Балтыйк буенда, Үзбәкстанда, Кыргызстанда, Төркмәнстанда, Украинада, Азәрбайҗанда яшәүче татарлар милләтнең язмышын, республиканың статусын уңай якка хәл итүгә нинди йогынты ясый алалар? Ачы булса да аша — үз куагың җимеше, дигәндәй, турысын әйтик: бу йогынты бүрәнә аркылы бүре куугa да тигезләнә алмый. РСФСРның ерак төбәкләрендә яшәүче милләттәшләребез дә кискен, хәлиткеч вакытта җөмһүриятебезгә терәк булудан мәхрүм. Әгәр милләт борынгы бабаларыбыз тупланып яшәгән төбәкләргә — Идел, Агыйдел, Чулман буйларына кайтып төпләнүне ашыктырмыйлар икән, хәлебез һаман да хөрти килеш калачак.

Дөрес, фатир алыштырулар, йорт сатулар һәм яңасын төзүләр, күченүләр гаять мәшәкатьле эш. Ләкин бу авырлыкларны кайсы да булса буын кичерергә тиештер бит! Киләчәк буыннарга калдырабыз икән бу эшне — өмет икеләтә-өчләтә кими. Чөнки аларның телгә, гореф-гадәткә, мәдәниятка карата мөнәсәбәтләре «таҗка үлчим» чамасында гына булачак. Яшерен-батырын түгел, күпләргә ихтыяри-мәҗбүри дә кайтырга туры килмәгәе! Күреп торабыз лабаса, һәр милләт үз төбәгендә үзе генә яшәргә омтыла. Инде чираттагы сорауны да бирергә вакыт җитте. Я әйтегез, кем кадерлерәк булачак Татарстанда: үзенең, милләтенең хәлен алдан ук кайгыртып кайткан кешеме, әллә куылгач, артына тибелгәч кенә кайтып егылганымы?

Читтә яшәүче кайбер милләттәшләр:


— Без бит Татарстаннан тормыш авыр булганга киттек, — диләр. Килешәбез. Әмма монда калганнар да майлы калҗа ашап яшәмәде бит!

Күмәк коллективлаштыру елларында сталинчылар тарафыннан куылган-сөрелгән нәселләр барлыгын да истә тотабыз. Ләкин милләт кумаган бит аларны. Димәк, әллә кайда еракта үпкәләп яшәргә нигез юк. Туган як капкалары һәркемгә тигез дәрәҗәдә ачык.

Сизеп торам, кайбер милләттәшләрнең ачуы кабара. Янәсе: «Ике күчү бер януга тигез ул, туганкаем!» Беләм, бик беләм. Дүрт гасыр ярым буе чәчелгән халыкны туплау чорында матди яктан гына янарга туры килмәячәк әле кайбер милләттәшләргә, анысын да беләм...

Илле-йөз ел чамасы алга карыйм да сискәнеп куям. Әгәр без бүген милләтнең язмышы, киләчәге турында бердәм булып кайгыртмыйбыз икән һәм ниндидер сәбәпләр милләтне үстерү, туплау өмәлен бетерә икән, безнең оныклар хәзерге буынны каһәрләп кенә искә алачаклар. «Шундый форсатны кулдан ычкындырганнар бит безнең бабайлар!» — дип көенәчәкләр.

Тик ул вакыт «Кая китә бу татар?!» дип өзгәләнү дә файда бирмәячәк. Инде ул киткән булачак...



Фәнзаман БАТТАЛ

ФОТО информация




Рәсемдә сигаралар җитештерүче Джино Давидофф кәефләнеп кенә тартырга җыена. Тик аның сигарасы Кубада үстерелгән тәмәкедән түгел. Джино «яңа» сигаралар өчен чималны Доминика Республикасыннан ала башлады.



«Шаккатырлык рекорд»— Цюрихта шушындый девиз белән спортның экзотик төрләренә конкурс үткәрелде.

Рәсемдә: Швейцариядән килгән Джо Александер өсте-өстенә өелгән 13 кирпечне терсәге белән сугып вата.



Безнең кибетләрдә азык-төлек юк дип бер дә кайгырмагыз. Рәсемдәге французга охшасагыз, мондый борчылулар бик тиз онытылыр. Ул менә биш ел инде иректә яшәгән шимпанзелар кебек җиләк-җимеш, яшелчә, яфрак-тамырлар һәм... бөҗәкләр белән туклана. Ул коңгыз, суалчан, саранчаларны яратып ашый.



Америка — могҗизалар иле. Монда кеше ышанмастай хәлләргә дә тап буласың. Биредә «гигантлар узышы» үткәрелде. Анда буе 75 мм.га җиткән зур-зур тараканнар катнашты. «Куып тоталмассың» исемле таракан җиңеп чыкты,

ТАСС фотохроникасы.

Сабыр төбе... сары ялкын?

(ХАТЛАР КҮЗӘТҮ)

Эштән кайтып ашарга әзерләп йөри идем, бер танышым сугылды.
— Митингка ашыгам, — ди бу, — ә син бармыйсыңмыни?
Ничектер, сәер булып китте. Әллә кайчаннан күзләребезгә бәрелеп торган элеккеге бер плакат һәм аның астындагы «Син үз иркең белән Кызыл Армиягә язылдыңмы?» дигән куркыныч, шомлы сорау хәтергә килде. Без хис белән яшәүчеләр. Күңелебезнең астын-өскә әйләндерү өчен безгә күп кирәкме? Ә хисләр, эмоцияләр өстенлек иткән җирдә салкын акыл сине тыңламый.

Сәясәт һәркем өчен түгел. Ул шушы эшкә бөтен барлыгын багышлаган аерым шәхесләр өчен. Ләкин бүген сәясәттән ничек кенә ераграк булырга тырышма, ул барыбер мәҗбүриләп синең бусагаңнан атлап керә, бөтен күңелеңне, тормышыңны биләп ала. Болгавыр дөнья. Дөнья кебек үк, фикерләрнең дә иң болганган чагы. Мондый чакта кем хаклы, кем хаксыз икәнлеген ачыклавы да кыен. Һаман саен хакимлеккә омтылып, әле анда, әле тегендә көрәш кыза, бәхәсләр кыза, ә тормыш, безнең көндәлек тормышыбыз яхшырмый, киресенчә, тагын да көйсезләнә бара. Ул гынамы әле, власть өчен көрәшкә һәммә кешене тартып кертмәкчеләр. Керергә теләмәсәң, хәзер ярлык тагалар: син безнең белән түгел, димәк, дошман ягында. Арыган, тормыш яхшыруын көтә-көтә талчыккан халык кай тарафка сугылырга белми азаплана.

Үз арабызда дошман эзләми генә, җан көйдергеч бәхәсләрдән башка гына яшисе иде дә. Күңелеңә хуш килерлек хезмәтең белән кешечә яшисе иде. Берәүнең дә гомере ике килми. Шул бердәнбер гомеребезне ызгыш-талашларга, мәңгелек бәхәсләргә сарыф итмичә, тату гына яшисе иде дә бит...

Юк шул. Һаман (инде кайчаннан бирле!) яшәргә дип азапланабыз, тормыш яхшыруын көтәбез, өметләнәбез. Ә өметләр һаман акланмый.

Менә алдымда бер кочак хат. Әрнүле, аптыраулы, икеләнүле хатлар. Апрель реформасыннан соң хатлардагы әрнүләр, өметсезлекләр бермә-бер артты. Казаннан С. Вәлиева шалтырата: «Инде ике ел буе өйдә ремонт тәгәлли алмыйм. Әле берсе, әле икенчесе юк. Өйдә мәхшәр. Кайда нәрсә барын да белмим. Кайтып керәсем килми...»

Таныш һәм ялыктыргыч күренеш ул ремонт дигәнең. Шулай да әле бер фатирны гына ничек тә ерып чыгарсың. Ә менә илкүләм ремонт шулай билгесез вакытка сузылса, ни хәл итәргә? Безнең бүгенге тормыш нәкъ шундый ремонтны хәтерләтә. Әйтерсең лә башладылар да ташладылар. Ни тәртип, ни җаваплылык — берсе дә калмады. Бөтен өлкәдә шулай. Демократия дигән матур төшенчә йөгәнсезлек дигәне белән алышынды. Беркөнне Казан тирәсе урманында ике абзый рәхәтләнеп яшь наратларны кисеп маташалар. Янында арба тора. Төя дә алып кайт. Сүз әйтүче дә юк, дәүләтнеке, димәк, берәүнеке дә түгел.

Күршем кергән. «224-нче кибеттә көнбагыш маен ике көн буе 3 сум 70 тиеннән саттылар,—ди. — Белмәгән белмәде, ә мин кызыксындым, кибет директоры янына кереп белештем. Ачулары килде килүен. Ләкин шуннан соң 2 сум 70 тиенгә төшерделәр...»

Ә Казан елгасы буенда инде язга чыкканнан бирле тал ботарлыйлар. Олысы да, алардан күреп, кечесе дә. Башта тал песиләре өчен ботарладылар, ә хәзер яр буенда учак ягар өчен... Йөгәндә торырга ияләшкән халык йөгәнсезлекне бик тиз сизде. Кылана алган теләсә ни кылана. Контроль дә, закон да — ләм-мим. Ә хезмәт белән көн күрергә өйрәнгән, намус төшенчәсе, бурыч, вөҗдан төшенчәләре борчыган халык аптырауда. «Кая бара бу дөнья? — дип гаҗизләнеп яза Буадан Вәлиулла абзый, — базар бәясе диләр дә күсәк белән башка сугалар. Иләге, көрәге, сәнәге дигәндәй — бөтенесе кыйммәтләнеп бетте. Ничек яшәргә соң безгә?»

Ничек яшәргә? Шушы сорау йөзләрчә хатлар өчен уртак. «Элек патшаларга ләгънәт укыганнар. Бүген кем соң патша? Бүгенге болгавырлык өчен кемгә ләгънәт укырга?»— дип сорый Казанда яшәүче Сәлимә Җаббарова. «Сугыш чорларында сугыш дип ач яшәдек, хәзерге ачлык-ялангачлыкны нәрсә белән аңлатырга?»—дип аптырый Пермь өлкәсенең Чайковский шәһәреннән Рәхимҗан Ибәтуллин.

Әйе, бәяләр күтәрелүе дә, илдә, җөмһүриятебездә барган сәяси, икътисади каршылыклар да — бөтенесе хезмәт кешесе өчен тормышның көтелмәгән сынавы булды. «Бәяләр күтәрелү безгә, авылда яшәүчеләргә, икеләтә авыр, — ди Әлмәттән Фирая ханым. — Әле икмәк арзан чакта да шәһәрдән ташып ашаган авыл халкы хәзер терлек тә асрый алмаячак. Безгә бит талоннар да бирелми. Көннән-көнгә ялгаулары да кыен. Ничек яшәргә? Онның гына да килосы 1 сум 40 тиен булсын әле, ул 60 сум компенсация белән нишләп була? Хөкүмәтнең бу политикасы халыкның хәле турында кайгыртуга түгел, халыкны үтереп бетерүгә юнәлтелгән».

Ризасызлык, җан ачысы — һәр өч хатның берсендә. Менә Түбән Кама «Шин» берләшмәсе эшчеләре Рәсимә Шәнтова, Гөлсем Гафиятуллина, Нәзирә Ямалова, Зинаида Чуйко һәм башкалар исеменнән язылган күмәк хат: «Без өч сменалы эштә станок артында эшлибез. Планнарны 110—130 процентка арттырып үтәп барабыз. Шулай эшләп тә безнең хезмәт җимеше кая китә икән соң? Ә бит җөмһүриятебездә безнең кебек эшчеләр азмыни? Һаман кибет киштәләре буп-буш, ничек яшәргә? Барыбызның да гаиләсе, икешәр-өчәр баласы бар. Эш хакыбызга, хөкүмәт биргән компенсациягә 4—5 тапкыр күтәрелгән бәядән балаларга кием алыргамы, әллә базардан витаминлы ризыкмы? Югарыда утыручылар! Безнең сабырлыгыбызны соңгы чигенә җиткермәгез!»

Алга таба ни булыр? Ничек яшәрбез? Күпләр шушы сорауга җавап таба алмаудан гаҗиз. Урындагы аппарат әгъзаларының халык мәнфәгатьләрен санга сукмавы, җавапсызлыгы күңелгә кереп утырган шик-шомлануларны киметми, киресенчә, тагын да арттыра, чарасызлыкны көчәйтә. «Гаделлек юк инде ул, булмады, булмас та, — дип ачына Чаллыдан 23 яшьлек Гөлгенә. — Моңарчы рәхәт яшәгәннәр генә рәхәт яши. Ә бер интеккән гомер буе интегә. 60 сум компенсация биреп тончыгыгыз диделәр дә шуның белән шул. Ә монда бәяләр илгә-кырга сыймый! Бар булган керем 100 сум! Шуңа аша, киен, рәхәтлән, совет гражданины! Рәхәтләнеп яшисе урында нишләргә дип аптырап утыр әле...»

Дөньяның төзексезлеге, җитәкчелектә утыручыларның булдыксызлыгы, салкын битарафлыгы әнә шундый Гөлгенәләрнең җилкәсенә авыр йөк булып ята, яшьне дә, инде тормыш тәҗрибәсе туплаган кешеләрне дә рухи төшенкелеккә китерә. Менә тагын бер мисал. «Утыз ел инде үзебезнең совхозда терлекчелектә эшлим, — дип укыйбыз Саба районы, Олы Кибәче авылыннан Фәрук Камалов язган хаттан. — Бер улым Әфганстанда хезмәт итеп саулыгын югалтып кайтты. Икенчесе Камчаткада хезмәт итә. Гомер буе иске өйдә яшәдек. Ул җимерелгәч, леспромхоздан агач алып йорт җиткердем. Ләкин яңа йортның түшәме, идәне әзер түгел. Борыслык кирәк. Шуларны юллап леспромхоздан министрлыкка җиттем. Кайда да «юк» дигән җавапны гына ишетәм. Инде сабырлыгым да, көчем дә калмады. Йортыма ут төртәм дә, үзем дә кереп янам...»

Гомер буе хезмәт белән чиләнеп яшәгән кешенең үткәненә ясаган нәтиҗәсе әнә нинди.

Әлегә шулай яшибез. Бер яктан сәясилек, икенче яктан хәерчелек, җавапсызлык. Итекче дә, пешекче дә, әби-бабайлар да иртән торып күзен ачуга сәяси тормыш белән кызыксына икән, бу инде нормаль хәл түгел. Җәмгыять сәясиләнә барган саен икътисад җимерелә бара дигән фикернең хаклыгын тарих мең кат исбатлаган.

Шулай да күзәтүне төшенкелек белән тәмамлыйсы килми. Күңелдә өмет, зирәк фикернең барыбер өстен чыгасына ышаныч бетмәгән әле.

Рина ЗАРИПОВА.

Кайда сез, «усал» укытучылар!

Бу язмамны башлау өчен кулыма каләм ала алмыйча шактый вакыт йөрдем. Мин үз-үземә сорау куйдым: «Балалар дөньясын дөрес аңлыйммы, чамасыз кырыс түгелме мин, замана үзгәрә, бәлки, мәктәп тормышы да шулай булырга тиештер?»

Март аеның матур гына бер көнендә мәктәп балалары белән циркка барырга туры килде. Автобуслар озак көттерде.

Юлдагы тәртипсезлеккә, олыракларның кечерәкләрне кыерсытуына ис-акыл китәрлек булды. Армиядә генә түгел, Бәтке урта мәктәбендә дә «дедовщина» дигән нәрсә барлыкка килгән икән. Интернатта кечерәкләрнең киемнәрен ягу дисеңме, кроватьларын салкын якка чыгарып газап чиктерүме — берсе дә калмаган. Шуңа күрә башка авыллардан йөрүчеләр качып кайтып китә торган булдылар. Ә бит балалар интернатта тормаса да, төнге нянялар, тәрбиячеләр штатта бар, балалар өчен тукlануга бирелгән продуктлар тиешенчә алып барыла. Тик укытучыларның гына бернәрсәгә исе китми. Тиешле сәгатен укыткач, үзен мәктәпкә бәйле диеп белми, журналын атып тизрәк өенә ашыга. Балаларның мәктәптән тыш вакытлары белән, ант итәм, беркем дә, беркайчан да кызыксынмый. Шуңа да балалар шәһәрдә генә түгел, авылда да кыргый төс ала баралар.

Йә ходаем, дим, күңелемнән, ник улымны бер ел алдан мәктәпкә бирдем, ул да бит мескенем 9 яшеннән шушы тәмуг газабын күрәчәк.

Бервакыт дүртенче сыйныф укучысы Илдар дигән малайны, бик сүгенгәч, тәртипкә чакырдым. Соңыннан ник әйткәнемә мең мәртәбә үкендем. «Ничава, — ди бу русчалатып, — малаең да Бәткегә йөри башлый, күрсәтәбез әле без аңа...»

Их, кайда сез, безнең усал дип исәпләгән кадерле укытучыларыбыз? Сез усал түгел, изге күңелле булгансыз икән, вакытыгызны жәлләмичә көннәр, айлар, еллар буена гомерегезне безгә багышлаган булгансыз. Мең-мең рәхмәт сезгә! Тик нигә укытучы һөнәре сайлаган укучыларыгызга «безнең кебек булыгыз» дип өйрәтмәдегез?

Миңлегөл НӘҖМИЕВА.
Балык Бистәсе районы, Кече Укмас авылы.

СЕЗ СОРАГАН ИДЕГЕЗ

Тынычланырга иртәрәк

«Татарстан АЭСын җылылык станциясе итеп үзгәртү эшләре башландымы? Ни өчендер анда куркыныч тынлык хөкем сөрә сыман...

М. ХАЛИКОВ.
Казан».

Бу сорауга җавап бирү өчен Татарстан атом электр станциясе төзелешен туктату буенча вакытлы комитет рәисе ярдәмчесе Әхмәт ЗАКИРОВ белән элемтәгә кердек.

— Әхмәт Закирович, әлеге сорауга ачыклык кертмәссезме!

— СССР Министрлар Советы тарафыннан 1990 елның 12 октябрендә Татарстан АЭСы төзелешен туктатып, аны җылылык станциясе итеп үзгәртү турында чыгарылган карарны республика халкы шатланып каршы алгандыр. Кама буендагы Чернобыль куркынычы бер адымга артка чигенде дип күңелләрне тынычландырдык. Ләкин Россия Федерациясе Югары Советындагы бер төркем авантюрачылар һаман да Союз хөкүмәте чыгарган карарны юкка чыгарып, үз теләкләрен т о р м ы ш к а ашырмакчылар. 1991 елның 21 февралендә Татарстан Югары Советы рәисе М. Шәймиевкә адресланган бер мәкерле хат кулга төште. Аңа РСФСР Югары Советының энергетика комитеты комиссиясе рәисе В. А. Федорченко имзасы куелган. Менә аның эчтәлеге: «Хөрмәтле Минтимер Шәрипович! РСФСР Югары Советының промышленность һәм энергетика буенча Комитетында «РСФСР территориясендә АЭС төзелеше турында»гы СССР Министрлар Кабинеты карары проекты тикшерелде. Шушы уңайдан Комитетка Татарстан АЭСы төзелешен дәвам итү һәм куркынычсыз блоклар урнаштыру тәкъдиме белән әлеге коллективтан мөрәҗәгать алынды. Газ бирүдәге гадәттән тыш чикләнгән мөмкинлекләрне һәм 1992 елда АЭСлар өчен куркынычсыз блокларның эшләнеп бетүен искә алып, АЭС төзелеше мәсьәләсен яңадан каравыгызны сорыйм. Бу хакта АЭС коллективына һәм безгә хәбәр итүегезне үтенәм».

Менә бит атомчылар ничек астыртын эш итмәкчеләр! Әйтерсең Минтимер Шәрипович Шәймиев мәсьәләне үзе генә хәл итә. Янәсе, Татарстан АЭСы коллективы үтенече белән! Халык исеменнән башкарылган планнардан без болай да ничек котылырга белмибез. Ә АЭСны җылылык станциясе итеп үзгәртү буенча эшләр кәгазьдә генә бара әлегә.

— АЭС коллективыннан шундый тәкъдим чыннан да булганмы!

— Тулы бер коллективтан булгандырмы, әллә үз мәнфәгатьләрен өстен куеп, атом куркынычы белән шаярырга омтылучы аерым кешеләр кулы белән эшләнгәндерме, әмма РСФСР Югары Советына шундый телеграмма җибәрелгән.

Уяулыкны югалтырга, тынычланырга иртәрәк безгә. Кем әйтмешли, дошман йоклап ятмый...

Татарстан АЭСын төзүчеләр һәм анда эшләячәк кешеләрнең үз-үзләренә һәм үзләреннән соңгы буыннарга атом афәте әзерләргә омтылуларына ышануы авыр. Уйлансын, белсен, аек акылга кемнең басымчылык итүен аңласын иде бирелгәге халык. Бүген кулга килеп кергән меңләгән сум хезмәт хакы, бүгенге яшәү шартлары, бүгенге фатирлар турында гына уйламаска, ә балалары, оныклары, кешеләр язмышы турында онытмаска иде аларга...

Булачак җылылык станциясенә килгәндә, аның бары тик газ ягулыгы белән эшләтүгә корылачагы турында Татарстан Югары Советы үз сүзен нык итеп әйтте бит инде.

Әңгәмәне Әлфия САМАТ язып алды.



Казан мәктәпләре укучылары игътибарына!

А. Н. ТУПОЛЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ КАЗАН АВИАЦИЯ ИНСТИТУТЫ «РАДИОПРИБОР» ТАТАР ПРОИЗВОДСТВО БЕРЛӘШМӘСЕ ИДЕЛ БУЕ РАЙОНЫНЫҢ 83 НЧЕ УРТА МӘКТӘБЕ МАТЕМАТИКА, ФИЗИКА, РАДИОЭЛЕКТРОНИКА, ИНФОРМАТИКА тирән үзләштереләчәк VII һәм VIII классларга укучылар кабул итә.

Мәктәптә кайбер фәннәрне КАИ укытучылары укытачак, лабораторияләр һәм кабинетлар институт һәм «Радиоприбор» берләшмәсе көче белән бик яхшы җиһазланган.

Гаризалар 10 нан 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Белешмәләр өчен телефон: **35-09-41**, мәктәпнең адресы: **Казан, Бертуган Касыймовлар урамы, 52.**

А. Н. ТУПОЛЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ КАЗАН АВИАЦИЯ ИНСТИТУТЫ ҺӘМ ВАХИТОВ РАЙОНЫНЫҢ КАИ КАРШЫНДАГЫ 96 НЧЫ УРТА МӘКТӘБЕ 1991 елның 3 июненнән 26 июнена кадәр VIII һәм X классларга укучыларны конкурс белән кабул итә.

Бу классларда математика, физика, информатика, физик культура, инженерлык иҗаты нигезләрен тирәнтен үзләштерәләр. Мәктәп, КАИның укытучылары һәм лабораторияләр базасыннан файдаланып, укучыларны техник вузларга керергә әзерли. Махсус классларны тәмамлаганда бирелгән чыгарылыш имтиханнары КАИга керү имтиханнары булып санала.

Мәктәптә математика, физика, чит телләр, кул сугышы сәнгате (каратэ, ушу һ. б.), экономик белемнәр, эшкуарлык нигезләре, автомобиль йөртү һәм медицина нигезләре буенча факультативларга югары класстагыларны кабул итү — 1991 елның 2 сентябреннән 11 октябрена кадәр.

Кабул итүне сорап, мәктәпкә гариза, 3×4 см зурлыктагы дүрт фоторәсем һәм өлгереш табелен алып килергә кирәк.

Белешмәләр өчен телефон: **36-17-23, 36-17-44.** Мәктәпнең адресы: **Достоевский урамы, 51.**

Кабул итү комиссиясе дүшәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрне 9 дан 12 сәгатькә кадәр эшли.

Казан шәһәренең 110 нчы урта профтехучилищесы (элеккеге 3 нче кичке профтехучилище

ПРОИЗВОДСТВОДАН АЕРЫЛМЫЙЧА КВАЛИФИКАЦИЯ КҮТӘРҮ БУЕНЧА УКЫРГА ТҮБӘНДӘГЕ БЕЛГЕЧЛЕКЛӘРГӘ ЭШЧЕЛӘР КАБУЛ ИТӘ:

Төп производство участогы бригадиры (металлны кисеп эшкәртү буенча).

Сәүдә һәм суыту җиһазлары буенча электромонтер.

Станок һәм слесарьлык эшләре контролеры.

Радиотелевизион аппаратларга хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау буенча радиомеханик (ак-кара һәм төсле сурәтле телевизорлар) — уку срогы 10 ай.

Электр һәм газ белән эретеп ябыштыручы.

Земснарядларның механик һәм электр җиһазлары машинисты — уку срогы 6 ай.

Училищега 10 класс белемле ир-ат һәм хатын-кызлар кабул ителә.

Уку бушлай.

Укучыларга ел дәвамында 30 эш көнлек уку ялы бирелә, 50 процент эш хакы саклана.

Укырга кергәндә түбәндәге документлар кирәк:

1. Предприятие юлламасы.
2. Директор исеменә гариза.
3. Белем турындагы документ.

Гаризалар 9 дан 18 сәгатькә кадәр көн саен кабул ителә.

Белешмәләр алу өчен адрес: 420020, Казан, Сул Болак урамы, 34 (ишегалды ягыннан керәсе).

Телефон: 32-58-50.

КАЗАН ШӘҺӘРЕНЕҢ 38 НЧЕ НОМЕРЛЫ ПРОФЕССИОНАЛЬ-ТЕХНИК УЧИЛИЩЕСЫ

кызларны һәм егетләрне түбәндәге белгечлекләр буенча [9—11 класс базасында] укырга чакыра.

— Җитен тарау машиналары операторы,
— тукучы,
— чорнау машиналары операторы,
— күн-галантерея әйберләр тегүче,
— трикотаж әйберләр бәйләүче,
— тегүче-мотористка,
— эрләүче.

Уку срогы 1—2 ел.

113—180 сум стипендия түләнә. Җитен тарау машиналары операторы, тукучы, чорнау машиналары операторы, эрләүче белгечлекләре буенча укучыларга барлык уңайлыклары булган тулай торактан урын бирелә. Производство практикасы вакытында эшләп алынган акча җитен комбинаты өчен әзерләнүче группалар укучыларына тулысынча, ә башка группалар өчен яртылаш түләнә.

Училищены тәмамлаганнан соң айлык эш хакы 350—550 сум тәшкил итә.

Безнең адрес: Казан шәһәре, Гладилов урамы, 59. СПТУ-38. Телефон: 55-32-01.



Хезмәт Кызыл Байрагы һәм Халыклар Дуслыгы орденлы, А. Н. Туполев исемендәге КАЗАН АВИАЦИЯ ИНСТИТУТЫ

1991 ЕЛГА I КУРСКА СТУДЕНТЛАР КАБУЛ ИТӘ.

Институтта укыту көндез һәм производстводан аерылмыйча кич укыту формасында алып барыла.

Көндезге бүлектә түбәндәге факультетларда инженерлар әзерләнә:

— ОЧУ АППАРАТЛАРЫ ФАКУЛЬТЕТЫНДА: машина төзелеше технологиясе, самолет һәм вертолет төзелеше (белгечлекләр: композицион материаллардан әйберләр проектлау һәм эшләү, менеджмент), ракета төзелеше.

— ОЧУ АППАРАТЛАРЫ ДВИГАТЕЛЬЛӘРЕ ФАКУЛЬТЕТЫ: авиация двигательләре һәм энергетика җиһазлары (белгечлекләр: һава-реактив двигательләрен җитештерү һәм конструкцияләү, авиадвигательләр җитештерү технологиясе, авиация двигательләренең җирдә кулланылышы, автомобильләр өчен эчке янулы двигательләр), ракета двигательләре (белгечлек: машина төзелешендә САПР), авиация һәм ракета-космик җылылык техникасы.

ОЧУ АППАРАТЛАРЫНЫҢ АВТОМАТИК ИДАРӘ СИСТЕМАСЫ ҺӘМ ҖИҺАЗЛАРЫ ФАКУЛЬТЕТЫ:

авиация приборлары һәм үлчәү-хисаплау комплекслары,

биотехник һәм медицина аппаратлары һәм системалары,

очу аппаратларының идарә һәм навигация системалары,

оптик приборлар һәм системалар,

робот техникасы системалары һәм комплекслары,

техник системаларда автоматика һәм идарә итү,

авиация-космик электр җиһазлары,

автомобильләрнең электрон һәм электр җиһазлары,

авиация һәм автомобильләр электр җиһазларын проектлауны компьютерлаштыру.

— ТЕХНИК КИБЕРНЕТИКА ҺӘМ ИНФОРМАТИКА ФАКУЛЬТЕТЫ:

гамәли математика,

хисаплау машиналары, комплекслары, системалары һәм челтәрләре,

информацияне эшкәртү һәм идарә итүнең автоматлаштырылган системалары (белгечлекләр: автоматлаштырылган информацион системалар, интеллектуаль системалар),

электрон хисаплау чараларын конструкцияләү һәм аларның технологиясе,

хисаплау техникасы һәм автоматлаштырылган системаларның программа белән тәэмин ителеше,

— РАДИОТЕХНИКА ФАКУЛЬТЕТЫ:

радиотехника (белгечлекләр: биомедицина электроникасы һәм лазер техникасы, квант электроникасы һәм лазер технологиясе),

радиоэлектрон чараларны конструкцияләү һәм җитештерү (белгечлекләр: РЭА конструкцияләү, РЭА җитештерү технологиясе),

радиотехник системалар һәм комплекслар (белгечлек: антенна системаларын проектлау).

— ИДАРӘ ИТҮ ҺӘМ ЭШКУАРЛЫК ФАКУЛЬТЕТЫ:

машина төзелеше экономикасы һәм идарә (белгечлекләр: предприятие белән идарә, җитештерүне оештыру, промышленность коммерциясе һәм тышкы экономик эшчәнлек),

экономик информатика һәм идарәнең автоматлаштырылган системалары (белгечлек: идарәнең информацион технологияләре).

Производстводан аерылмыйча институт түбәндәге белгечлекләр буенча инженерлар әзерли:

— машина төзелеше технологиясе, самолет һәм вертолет төзелеше, авиация двигательләре һәм энергетик җиһазлар, оптик приборлар һәм системалар, информация эшкәртү һәм идарәнең автоматлаштырылган системалары, радиотехника, радиоэлектрон чараларны конструкцияләү һәм аларның технологиясе.

Көндезге бүлеккә гаризалар 25 июньнән 15 июльгә кадәр, кичке бүлеккә 25 июньнән 19 августка кадәр кабул ителә. Институт ректоры исеменә язылган гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

— урта белем турында документның төп нөсхәсе яки нотариус раслаган күчермәсе;

— хезмәт кенәгәсенең администрация раслаган күчермәсе (хезмәт стажы булганнар өчен);

— медицина белешмәсе (086-У формасы);

— 3×4 см зурлыктагы алты фоторәсем.

Хатлар, белешмәләр өчен адрес: **420111, Казан, К. Маркс урамы, 10. Кабул итү комиссиясе.**

Ленин орденлы, Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы В. И. Ульянов—Ленин исемендәге КАЗАН ДӘҮЛӘТ УНИВЕРСИТЕТЫ

1991—1992 НЧЕ УКУ ЕЛЫНА ТҮБӘНДӘГЕ ФАКУЛЬТЕТЛАРНЫҢ БЕРЕНЧЕ КУРСЛАРЫНА СТУДЕНТЛАР КАБУЛ ИТӘ:



Биология-туфрак белеме факультетына түбәндәге белгечлекләр буенча: «Зоология», «Ботаника», «Физиология», «Генетика», «Биохимия», «Микробиология», «Агрохимия һәм туфракчылык белеме» (көндезгә уку).

География факультетына түбәндәге белгечлекләр буенча: «География»—фәнни-педагогик һәм фәнни-җитештерү цикллары (көндезге уку), фәнни-педагогик цикл (читтән торып уку), «Метеорология» (көндезге уку).

Геология факультетына түбәндәге белгечлекләр буенча: «Геологик сурәт алу, эзләнүләр һәм разведка», «Эзләнүләрнең һәм разведканың геофизик ысуллары», «Нефть һәм газ геологиясе».

Тарих факультетына түбәндәге белгечлекләр буенча: «Тарих» (көндезге һәм читтән торып уку), «Социология» (көндезге уку).

Физика факультетына түбәндәге белгечлекләр буенча: «Физика», «Астрономия», «Астрономогеодезия» (көндезге уку), «Радиофизика һәм электроника» (көндезге һәм кичке уку).

Химия факультетына түбәндәге белгечлек буенча: «Химия» (көндезге уку).

Юридик факультетка түбәндәге белгечлек буенча: «Хокук белеме» (көндезге уку һәм читтән торып уку).

Хисаплау математикасы һәм кибернетика факультетына түбәндәге белгечлекләр буенча: «Гамәли математика» (көндезге һәм кичке уку), «Икътисади (экономик) кибернетика» (көндезге уку).

Филология факультетына түбәндәге белгечлекләр буенча: «Рус теле һәм әдәбияты», «Милли (татар) мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты» (көндезге һәм читтән торып уку).

Татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультетына түбәндәге белгечлек буенча: «Татар теле һәм әдәбияты» (көндезге һәм читтән торып уку).

Экология факультетына түбәндәге белгечлек буенча: «Тирә-юнь мохитны саклау һәм табигать байлыкларыннан дөрес файдалану» (көндезге уку).

Журналистика факультетына түбәндәге белгечлек буенча: «Журналистика» — рус һәм татар бүлекләре (көндезге һәм читтән торып уку).

«Журналистика» белгечлегә буенча иҗади конкурс материалларын кабул итү— 25 июньнән 15 июльгә кадәр. Иҗади конкурсның I һәм II турларын үткәрү — 9 июльдән 19 июльгә кадәр.

Гаризалар кабул итү:

— көндезге бүлеккә 25 июньнән 15 июльгә кадәр,

— кичке һәм читтән торып уку бүлегенә 25 июньнән 12 августка кадәр.

Кабул итү имтиханнары:

— көндезге бүлеккә 16 июльдән 31 июльгә кадәр,

— кичке һәм читтән торып уку бүлекләренә 13 августтан 24 августка кадәр.

Кабул итүне сорап бирелгән гаризалар ректор исеменә махсус университет бланкына языла. Гаризага өстәп түбәндәге документлар бирелә:

— урта яки югары уку йортын тәмамлау турында документ — төп нөсхә яки нотариаль расланган күчермә;

— 086-У номерлы медицина белешмәсе;

— хезмәт кенәгәсеннән күчермә (хезмәт стажы булганнар өчен);

— 3×4 см үлчәмле алты фоторәсем.

Паспорт, хәрби билет яки теркәлү турында белешмә университетка килгәч шәхсән күрсәтелә.

Адрес: 420008, Казан шәһәре, Ленин урамы, 18. Казан дәүләт университеты, кабул итү комиссиясе. Белешмәләр өчен тел.: 32-40-31.

Кабул итү комиссиясе.

Баш мөхәррир урынбасары Миңназыйм СӘФӘРОВ.



ЯЗЫГЫЗ:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2, «Татарстан яшьләре».

ШАЛТЫРАТЫГЫЗ:

Баш мөхәррир урынбасары — 53-07-52 (Миңназыйм Сәфәров).

Баш мөхәррир урынбасары — 53-07-50 (Раис Насыйбуллин)

Җаваплы сәркатип — 53-07-50 (Айрат Салаватуллин).

Көн яңалыклары, вакыйгалар — 53-07-56 (Айрат Садыйк).

Хатлар — 53-07-58 (Рина Зарипова Раилә Гаязуллина).

Иҗтимагый тормыш — 53-07-56 (Флюра Низамова).

Сәяси тормыш һәм тәрҗемә — 53-07-54 (Роза Шәрәфиева).

Фән, мәгариф — 53-07-54 (Нәсимә Мөхәммәтсадыйк).

Табигать, авыл тормышы — 53-07-52 (Әлфия Самат).

Мәдәният-сәнгать — 53-07-54 (Мансур Мортазин).

Фотохәбәрче — 53-07-48 (Евгений Канаев).

Рәссам — 53-07-48 (Зоя Хәялиуллова).

Корректорлар — 53-07-48 (Илсөяр Гарипова, Альмира Зәйнуллина).

Машинисткалар — 53-52-34 (Гөлчәчәк Җәләева, Хәлидә Миңһаҗева)

Баш бухгалтер — 53-07-59 (Рәмзия Хәбибуллина)

«Татарстан яшьләре»нең учредителе — ВЛКСМның Татарстан республика комитеты. Газета атнага өч тапкыр — сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга. Индекс—54121.

Редакциягә килгән материаллар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

Тираж 250.000. КПССның Татарстан республика комитеты нәшрияты типографиясендә басылды. Казан, Декабристлар урамы, 2. Заказ 5013.